МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 168/о

П Р И К А З Б О Е Р Ы К

«05» 10 2015

**“Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2012 елның 14 мартындагы “Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыкларының региональ кадастрын алып бару тәртибен раслау турында” 55/о номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында”**

2015 елның 6 апрелендәге “Хуҗалык җәмгыятьләренең мөһер зарурлыгын гамәлдән чыгару өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 82-ФЗ номерлы Федераль закон, 2005 елның 31 декабрендәге “Вәкаләтләрнең чикләрен билгеләүне камилләштерү сәбәпле Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 199-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының 2011 елның 30 сентябрендәге “Дәүләти калдыклар кадастрын алып бару тәртибен раслау турында” 792 номерлы боерыгы нигезләмәләре нигезендә

**б о е р ы к б и р ә м**:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2012 елның 14 мартындагы 55/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыкларының региональ кадастрын алып бару тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Региональ калдыклар реестры Татарстан Республикасының региональ классификация каталогын, Татарстан Республикасының региональ калдыклар урнаштыру реестрын, Татарстан Республикасы территориясендәге калдыклар турында һәм төрле калдык төрләрен файдалану һәм зарарсызландыру технологияләре хакында белешмәләр банкын үз эченә ала”;

2.3 пунктын “юридик затлар” сүзләреннән соң “һәм шәхси эшмәкәрләр” сүзләре белән тулыландырырга;

2.4 пунктын “юридик затларның” сүзләреннән соң “, шәхси эшмәкәрләрнең” сүзләре белән тулыландырырга;

3.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Калдыкларның конкрет төрләре РККОда аталышлары белән, ә аларның классификация билгеләре һәм куркынычлылык класслары – 11-санлы система буенча кодификацияләнгән рәвештә бирелгән.

Калдыкларның төре калдыкларның региональ классификация каталогында түбәндәге рәвештә чагылдырыла:

| Калдыклар төренең коды | Калдыклар төренең аталышы |
|---|---|

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | X | X | X | X | X |

Калдыклар төренең коды 11-санлы структурага ия:

РККО өчен калдык төрләренең классификация билгеләрен кодлаштыру түбәндәге рәвештә башкарыла:

X блогы,
XX тибы,
XXX тип өлеше,
XXX XXX төркеме,
XXX XXX XX төркемчәсе,
XXX XXX XX XX позициясе.

Блокларны, типларны һәм тип өлешләрен кодлаштыру өчен, тиешенчә, 1дән 9 кадәр саннар; 1дән 999 кадәр төркемнәр; 1дән 99 кадәр төркемчәләр кулланыла.

11-санлы кодның тугызынчы һәм унынчы билгеләре калдык төрләренең агрегат торышын һәм физик рәвешен кодлаштыру өчен кулланыла: 00 – мәгълүматлар юк; 01 – каты; 02 – сыек; 03 – пастасыман; 04 – шлам; 05 – гель, коллоид; 06 – эмульсия; 07 – суспензия; 08 – таралучан; 09 – гранулят; 10 – комсыман; 11 – тузансыман; 12 – сүс; 13 – кулланырлык үзлеген югалткан әзер эшләнмә; 99 – башкасы.

11-санлы кодның унберенче билгесе калдык төрләренең, әйләнә-тирә мохиткә булган тискәре йогынтысы дәрәҗәсенә карап, куркынычлылык классын кодлаштыру өчен кулланыла: 0 – калдыклар классификациясенең блоклары, типлары, тип өлешләре, төркемнәре, төркемчәләре һәм позицияләре өчен; 1 – I куркынычлылык классы; 2 – II куркынычлылык классы; 3 – III куркынычлылык классы; 4 – IV куркынычлылык классы; 5 – V куркынычлылык классы;

4.5 пунктының 5 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: “үләт базлары”;

4.6 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Калдыкларны урнаштыру объектларын эксплуатацияләүче җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, калдыкларны урнаштыру объектларының

милекчеләре, шулай ук калдыкларны урнаштыру объектларын биләүче яки алардан файдаланучы затлар калдыкларны урнаштыру объектларын инвентарьлаштыруны үткәрә һәм Министрлык гарызнамәләре буенча, әлеге Тәртипнең 1 кушымтасында күрсәтелгән рәвештә һәр калдыкларны урнаштыру объектына карата җитәкченең имзасы һәм оешманың мөһере (булган очракта) белән таныкланган мәгълүматларны тапшыра”;

4.8 пунктындагы “Җирле үзидарә органнары һәм юридик затлар” сүзләрен “Җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр” сүзләре белән алмаштырырга;

4.9 пунктында “юридик затлар” сүзләреннән соң “, шәхси эшмәкәрләр” сүзләре белән тулыландырырга;

4.11 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Калдыкларны урнаштыру объектының Реестрдагы номеры дефис белән бүленгән биш билге төркеменнән гыйбарәт, әгәр номер төркемендә саннар күләме биштән аз булса, сул яктагы чик сан алдыннан нульләр күрсәтелә.

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| А | А | - | Б | Б | Б | Б | Б | - | В | - | Г | Г | Г | Г | Г | - | Д | Д | Д | Д | Д | Д |

,

биредә:

АА – Россия Табигать министрлыгының 2010 елның 25 февралендәге 49 номерлы боерыгы (Россия Юстминистрлыгында 2010 елның 8 июнендә теркәлгән, теркәлү номеры – 17520) белән расланган Калдыкларны урнаштыру объектларын инвентарьлаштыру кагыйдәләренә карата 2 кушымтадагы таблица буенча машинада эшкәртү өчен билгеләнгән Россия Федерациясе субъекты коды;

БББББ – Россия Федерациясе субъекты территориясендә калдыкларны урнаштыру объектының тәртип саны;

В – калдыкларны урнаштыру объектының билгеләнеше: калдыкларны саклау – "Х" яки калдыкларны күмү – "З";

ГГГГГ – калдыкларны урнаштыру объектын Реестрга кертү турында Росприроднадзорның хокукый актының теркәү номеры;

Әгәр дә номер төркемендәге саннар күләме биштән аз булса, сул яктан чик сан алдына нульләр куела.

ДДДДДД – калдыкларны урнаштыру объектын Реестрга кертү турында Росприроднадзорның хокукый актын кабул итү көне, ае, елы;

елны күрсәтү өчен елның соңгы ике саны кулланыла;

V кисәк аталышын яңа редакциядә бәян итәргә: “Татарстан Республикасы территориясендә төрле калдык төрләрен куллану һәм зарарсызландыру технологияләре турындагы мәгълүматлар өлешендә Белешмәләр банкы”;

5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Татарстан Республикасы территориясендә төрле калдык төрләрен куллану һәм зарарсызландыру технологияләре турындагы мәгълүматлар өлешендә Белешмәләр банкы региональ калдыклар кадастры бүлегенең өлеше булып тора һәм Татарстан Республикасы территориясендә кулланыла торган җитештерү һәм куллану

калдыкларын куллану һәм зарарсызландыру технологияләре һәм объектлары турында системалаштырылган мәгълүматлар җыелмасыннан гыйбарәт һәм мондый технологияләрнең милекчеләре һәм (яки) эшләүчеләре тарафыннан ирекле тапшырыла торган, шулай ук аларны куллану әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясарга мөмкин булган тиешле яңа технологияләрнең техник документ проектларына дәүләти экологик экспертизасын үткәргәндә алына торган мәгълүмат нигезендә формалаша";

5.2, 5.3 пунктларын – көчен югалткан дип танырга;

5.4 пунктын "Юридик затлар" сүзләреннән соң "һәм шәхси эшмәкәрләр" сүзләре белән тулыландырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.4.1 пункты белән тулыландырырга: "Белешмәләр банкы Татарстан Республикасы территориясендә кулланыла торган җитештерү һәм куллану калдыкларын куллану һәм зарарсызландыру технологияләре турындагы мәгълүматлар өлешендә түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

а) технологиянең аталышы;

б) технологиянең билгеләнеше (калдыкларны куллану һәм (яки) зарарсызландыру);

в) калдыкларны куллану яки зарарсызландыруның технологик процессына кыскача сыйфатлама;

г) кулланыла торган ресурслар һәм калдыклар (электр энергиясе, кВт/с; су куллану, м3/с; калдыкларны куллану (зарарсызландыру), тонна (м3), елына);

д) РККО буенча кулланыла (зарарсызландырыла) торган калдыкларның аталышы һәм коды;

е) алына торган икенчел продукциянең (энергиянең) Икътисади эшчәнлек төрләре буенча продукциянең гомумроссия классификаторы (ОКПД) буенча аталышы һәм коды, башкасы (ОКПД буенча коды булмаганда);

ж) икенчел продукцияне (энергияне) алганда җитештерүчәнлек (үлчәү берәмлеген күрсәтеп, елына булган күләме);

з) ел дәвамында хасил була торган икенчел калдыкларның РККО буенча массасы (күләме), аталышы һәм коды;

и) технологияне эшләүченең (милекчесенең) адресы, телефоны, факсы, Интернет-сайты;

к) технологияне кулланучы юридик затның (шәхси эшмәкәрнең) адресы, телефоны, факсы, Интернет-сайты;

л) технологияне куллану (сәнәгать, сынау-сәнәгать, сынау, бүтәне);

м) технологиягә карата дәүләти экологик экспертиза бәяләмәсенең төп нәтиҗәсе, аның датасы һәм номеры, бәяләмәне биргән органның аталышы (дәүләти экологик экспертиза үткәргән очракта)";

VI кисәк аталышын яңа редакциядә бәян итәргә: "Татарстан Республикасы территориясендә калдыклар турында мәгълүматлар өлешендә Белешмәләр банкы";

5.5 пунктын – көчен югалткан дип танырга;

6.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Татарстан Республикасы территориясендә калдыклар турында мәгълүматлар өлешендә Белешмәләр банкы региональ калдыклар кадастры бүлегенең өлеше булып тора һәм калдыкларның хасил булуы, аларны куллану, зарарсызландыру, урнаштыру турындагы мәгълүматны үз эченә ала”;

6.2 пунктын “Белешмәләр банкы” сүзләреннән соң “мәгълүматлар өлешендә” сүзләре белән тулыландырырга;

6.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Татарстан Республикасы территориясендә калдыклар турында мәгълүматлар өлешендә Белешмәләр банкы, калдыкларны конкрет куркыныч классына кертүне билгеләнгән тәртиптә раслаган очракта, эшчәнлекләре процессында калдыклар барлыкка килә торган дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тапшырыла торган конкрет калдык төрләре турындагы мәгълүмат нигезендә формалаша һәм алып барыла”;

6.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Белешмәләр банкы калдыклар турындагы мәгълүматлар өлешендә түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

а) калдык төрләренең РККО буенча аталышы һәм коды;

(Калдык төрләрен калдыклар турында һәм төрле калдык төрләрен куллану һәм зарарсызландыру технологияләре турында белешмәләр банкына тапшыру эзлеклелеге РККО структурасына туры килә);

б) баштагы продукциянең аталышын күрсәтеп, аның нәтиҗәсендә калдык барлыкка килгән технологик процессның яки аның нәтиҗәсендә продукция үзенең кулланырлык үзлекләрен югалткан процессның аталышы;

в) калдыкның химик һәм (яки) компонент составы, процентларда;

г) калдык төренең агрегат торышы һәм физик рәвеше;

(Каты, сыек, пастасыман, шлам, гель, эмульсия, суспензия, таралучан, гранулят, комсыман, тузансыман, сүс, үзенең кулланырлык үзлекләрен югалткан әзер эшләнмә, башкасы);

д) калдыклар төренең куркынычлылык классы;

е) составы – минерал чималда күрсәтелгән төп тау токымнарының чама белән химик составы һәм килеп чыгышы – минерал чималда күрсәтелгән тау токымнарының, минерал чималны эшкәртү (куллану) нәтиҗәсендә хасил булган калдыкларның төре аны эшкәрткәндә (кулланганда) барлыкка килгән баштагы минерал чималның күрсәтелгән географик яту урыны (геологик провинциясе);

ж) калдыкларның төре турында башка белешмәләр.”;

6.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: “Калдыклар турында мәгълүматлар өлешендә белешмәләр банкы түбәндәге мәгълүмат нигезендә тутырыла:

Росстатның 2011 елның 28 гыйнварындагы “Росприроднадзор тарафыннан җитештерү һәм куллану калдыкларын федераль статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарий раслау турында” 17 номерлы боерыгы белән расланган “Җитештерү һәм куллану

калдыкларының хасил булуы, аларны куллану, зарарсызландыру, транспортлаштыру һәм урнаштыру турында мәгълүматлар" 2-ТП номерлы рәвеш (калдыклар) буенча оешмаларның белешмәләре;

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең 2015 елның 16 июлендәге "Эчке һәм тышкы сәүдәне федераль статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарий раслау турында" 321 номерлы боерыгы белән расланган "Кара һәм төсле металлар ломы хасил булу һәм аларны куллану турында мәгълүматлар" 14-МЕТ (лом) номерлы федераль статистик күзәтү рәвешендә оешмаларның белешмәләре;

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтнең 2013 елның 6 августындагы "Авыл хуҗалыгын һәм әйләнә-тирә табигый мохитне федераль статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарий раслау турында" 309 номерлы боерыгы белән расланган "Әйләнә-тирә мохитне саклауга карата агымдагы чыгымнар һәм экологик түләүләр турында мәгълүматлар" 4-ОС номерлы федераль статистик күзәтү рәвешендә оешмаларның белешмәләре;

8 бүлек аталышында "юридик затларның" сүзләреннән соң "һәм шәхси эшмәкәрләрнең" сүзләре белән тулыландырырга;

8 бүлекнең беренче абзацында "юридик затлар" сүзләреннән соң "һәм шәхси эшмәкәрләр" сүзләре белән тулыландырырга.

2. Юридик бүлек башлыгына (Э.Ю.Латыйпова) әлеге боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары М.М. Сәйфетдиновка йөкләргә.

**Министр** **И.Ә.Фәйзуллин**

ОТДЕЛ
РЕГЛАМЕНТА
И КОНТРОЛЯ
№1

КОПИЯ ВЕРНА
Оригинал документа хранится
в отделе регламента и контроля
Министерства строительства,
архитектуры и ЖКХ РТ

Ведущий специалист
отдела регламента и контроля
Иофоре Э.Ф.